| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ<br>ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** с.Старое Дрожжаное **КАРАР**

2021 елның 27 мае № 9/6

Цифрлы финанс активлары һәм цифрлы хокуклар турында белешмәләр тапшыру һәм керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрне бирү хакында аерым карарларга үзгәрешләр кертү турында

«Цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары турында» Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 10 декабрендәге 778 номерлы Указын үтәү йөзеннән Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. 2021 елның 30 июнен кертеп, түбәндәгеләрне билгеләргә:

- билгеләгәндә гражданнар керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирергә бурычлы булган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында муниципаль вазыйфалар Исемлегенә кертелгән Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында муниципаль вазыйфалар биләүне дәгъва кылучы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында муниципаль вазыйфалар биләүче, шулай ук Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының 2020 елның 30 гыйнварындагы 42/6 нчы номерлы карары белән расланган үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирергә бурычлы гражданнар;

- билгеләгәндә гражданнар керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирергә бурычлы булган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфалар вазыйфалар Исемлегенә кертелгән Татарстан Республикасы

Чүпрәле муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъва кылучы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче, шулай ук Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының 2012 елның 25 июлендәге 20/5 нче номерлы карары белән расланган үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирергә бурычлы гражданнар,

- муниципаль учреждениеләр җитәкчеләре вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар, муниципаль учреждениеләр җитәкчеләре вазыйфаларын биләүче гражданнар,

Россия Федерациясе Президентының “Керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмә формасын раслау һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында” 2014 елның 23 июнендәге 460 номерлы Указы нигезендә расланган белешмә формасы буенча бирелә торган белешмәләр белән бергә, “Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары хакында “Цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 10 декабрендәге 778 номерлы Указына 1 нче кушымта нигезендәге форма буенча үзләренең хатынның (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының цифрлы финанс активлары бер үк вакытта цифрлы финанс активлары һәм башка цифрлы хокуклар кергән цифрлы хокуклары, утилитар цифрлы хокуклары һәм цифрлы валютасы (булган очракта) турында хәбәрнамә тапшыралар.

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләрнең Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының 2014 елның 16 октябрендәге 44/2 номерлы карары белән расланган керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру турындагы Нигезләмәгә, **6 пунктның «в» пунктчасын** түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«в) хисап чорында (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта һәр объектны сатып алуга кагылышлы алыш-биреш буенча үз чыгымнары, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре, пайлар) турында, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы алыш-биреш башкарылганга кадәрге соңгы өч елда әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) гомуми кеременнән артып китсә, һәм алыш-биреш башкарылган акчаларны алу чыганаклары хакында белешмәләр.».

3. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының 2017 елның 25 августындагы 19/5 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында муниципаль вазыйфаларны һәм контракт буенча Башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен мәгълүмат бирү Тәртибенә, **3 пунктның «г» пунктчасын** киләсе редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«г) җир кишәрлеген, күчемсез мөлкәтнең бүтән объектын, транспорт чарасын, кыйммәтле кәгазьләрне, акцияләрне (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында катнашу өлешләрен), цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта сатып алу буенча алыш-биреш ясаган акчаларны алу чыганаклары, әгәр мондый алыш-бирешләр гомуми суммасы муниципаль вазифа биләүче затның һәм аның хатынының (иренең) соңгы өч елда гомуми кеременнән артып китсә, һәм алыш-бирешкылган акчалар алу чыганаклары турында белешмәләр.».

4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы аппаратына йөкләргә.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль
районы Башлыгы, Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы Советы Рәисе: М.Р. Гафаров